КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль г.Казань № 185

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 29 сентябрь, 923 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмиятле эшчәнлек алып баручы ветераннар, инвалидлар һәм пенсионерлар иҗтимагый оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан

Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Сайлап алуны үткәрү максатларында, Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын һәм электрон почта адресын;

ирешү өчен әлеге Тәртипнең 3.9 пунктында каралган субсидия бирү нәтиҗәсен (алга таба – субсидия бирү нәтиҗәсе);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документларны иҗтимагый оешмаларга карата таләпләр һәм документлар исемлеге (әлеге Тәртипнең 2.2 һәм 2.3 пунктлары нигезендә);

әлеге Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә иҗтимагый оешмалар тарафыннан бирелә торган гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр һәм гаризалар бирү тәртибе;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 2.5 – 2.7 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

иҗтимагый оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) социаль әһәмиятле эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле җәмәгать оешмалары чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә яисә каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүгә кул куярга тиеш булган, Министрлык һәм иҗтимагый оешма арасында төзелә торган, аңа карата субсидия бирү турында карар кабул ителгән (алга таба - Субсидия бирү турында килешү);

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) Субсидия бирү турындагы килешүне төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда һәм шулай ук сайлап алу җиңүчесен (җиңүчеләрен) билгеләгән көннең иртәгесеннән соң килүче 14 нче календарь көннән

соң була алмый торган Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру датасы.

Сайлап алуны үткәрү чорында сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләре, әгәр дә сорату Министрлыкка заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча керсә, Министрлык тарафыннан иҗтимагый оешмаларга Министрлыкка тиешле сорату кергән датадан биш эш көне эчендә электрон документ рәвешендә кергән соратуда күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки язма рәвештә кергән соратуда күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә бирелә.»;

2.2 пунктның җиденче абзацында «ирешелгән» сүзенә кадәр «мәгънәсенә» сүзен өстәргә.

2.3 пунктның уналтынчы абзацында «ирешелгән» сүзенә кадәр «мәгънәсенә» сүзен өстәргә.

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«аның мөрәҗәгате әлеге Тәртипнең 2.2 - 2.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында карар кабул иткән иҗтимагый оешмага (оешмаларга) бирелә торган субсидиянең (субсидияләрнең) күләме (күләмнәре).”;

2.7 пунктының алтынчы абзацында «чыгымнарның юнәлеше, финанс тәэминаты чыганагы белән туры килмәве» сүзләрен «чыгымнарның (тотылган акчаның) финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы белән туры килмәве» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның сигезенче абзацында «субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү» сүзләренә алмаштырырга;

3.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирүнең нәтиҗәсенә ирешү мониторингын үткәрү, Субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең һәм субсидия (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле проектны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгаларның күрсәткечләренә ирешүдән чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләр буенча мониторинг үткәрү.».

3.10 пунктта «ирешелгән» сүзенә кадәр «мәгънәсенә» сүзен өстәргә.

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Субсидия алучы Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең (шартнамәләрнең) үрнәк формаларында билгеләнгән рәвешләр буенча субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү турында һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр хакында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы арта барган нәтиҗә белән төзелә торган субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра, хисап елының I - III кварталлары өчен - хисап кварталыннан соң килүче 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, хисап елының IV кварталы өчен - хисап елыннан соң килүче елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча.»;

5.1 пунктның беренче абзацында «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

5.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия (чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия биргәндә) торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында

хисап тапшырмау, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле субсидияләр һәм күрсәткечләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап һәм өстәмә хисаплылык бирү хакындагы хисап тапшырмау, шулай ук күрсәтелгән хисапларны тапшыру сроклары бозылганда - тулы күләмдә;».

2. Бу карар (әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктының егерме дүртенче - егерме бишенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин